| Республика Татарстан<br><br>Совет Менделеевского муниципального района | | Татарстан Республикасы<br><br>Менделеевск муниципаль районы Советы |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.09.2024 Менделеевск ш № 269

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының « Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча 2024 елның 8 августындагы беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар бәяләмәсе нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1.Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының « Монай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru/ һәм расланган документны Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2013 елның 5 июнендәге 79 номерлы, 2020 елның 3 ноябрендәге 21 номерлы, 2021 елның 8 июнендәге 61 номерлы карарларын үз көчләрен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының икътисад, сәнәгать, ТКХ, төзелеш һәм элемтә мәсьәләләре буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе Р.И. Беляев